ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.11.2024 Казан ш. № 94-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 2023 елның 13 ноябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 13 ноябрендәге 134-од номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 2024 елның 17 сентябрендәге 79-од номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

1 пунктчада «Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча хисаплылыктан өземтәләр» сүзләрен «белешмәләр» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктчада «, бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^{1}$ статьясы нигезендә алар буенча билгеләнгән пенялар һәм штрафлар буенча дебиторлык бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчаның алтынчы абзацында «, гражданинның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында Банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчаның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән чоры узуга бәйле рәвештә дә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган, Татарстан Республикасы бюджетына бюджет түләүләрен, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясы нигезендә алар буенча билгеләнгән пенялар һәм штрафларны түләү буенча дебиторлык бурычларын түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Ветеринария идарәсе белешмәләре Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәсе тарафыннан раслаучы документлар алынган мизгелдән соң бер ай эчендә Комиссиягә җибәрелә.»;

7 пунктта «Хисаплылыктан өземтәләрне» сүзләрен «Белешмәләрне» сүзенә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә 1 нче кушымтада «бюджет керемнәренең баш администраторы (администраторы) буларак Ветеринария идарәсе хисаплылыгыннан өземтә» сүзләрен «Ветеринария идарәсе белешмәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.Н.Ногыманов